ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**25.06.2018**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1315**

Рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү турында

Т.Ф.Вәлиевның 16:49:012019:11 кадастр номерлы җир кишәрлегендә рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү турындагы мөрәҗәгатен карап, 2004 елның 29 декабрендәге Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 190-ФЗ номерлы, «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре нигезендә, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы бәяләмәне исәпкә алып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ**:

1. Т.Ф.Вәлиевка 16:49:012019:11 кадастр номерлы җир кишәрлегендә рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрларыннан , кишәрлек чикләреннән торак йортка кадәр көнчыгыш ягыннан 5 метрдан 0 метрга кадәр һәм төньяк яктан 5 метрдан 0 метрга кадәр минималь тайпылышларны киметү өлешендә, читкә тайпылуга рөхсәт бирергә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының (http://pravo.tatarstan.ru)рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Д.А. Сапожников

Рөхсәт ителгән төзелешнең чикле параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт алу мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә.

Зеленодольск шәһәре, ЗМР БК, Ленин ур., 41а 23.05.2018 ел, 16.00 сәгать

«Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре, «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы, Зеленодольск шәһәре Башлыгының 2018 елның 19 апрелендәге «Рөхсәт ителгән төзелешнең чикле параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт алу мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында» 02-03-08 номерлы карары нигезендә, 116:49:012019:11 кадастр номерлы җир кишәрлегендә рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт алу мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар үткәрелде.

Гавами тыңлауларны билгеләү турындагы карар «Зеленодольская правда» газетасында басылып чыкты һәм хокукый мәгълүматның Интернет челтәрендәге рәсми сайтында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырылды.

Рөхсәт ителгән төзелешнең чикле параметрларыннан тайпылуга рөхсәт алу мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар уздыру өчен кирәкле барлык процедуралар тиешенчә үтәлде.

2018 елның 23 маенда 16.00 сәгатьтә Зеленодольск шәһәре, Ленин урамы, 41А йорт адресы буенча рөхсәт ителгән төзелешнең чикле параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт алу мәсьәләсе буенча җир кишәрлеге милекчесе, шәһәр предприятиеләре һәм оешмалары җитәкчеләре, башка кызыксынучы затлар катнашуында гавами тыңлаулар үткәрелде .

Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча Зеленодольск шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару буенча эш төркеме

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Гавами тыңлаулар үткәрелде дип санарга;
2. Т.Ф.Вәлиевка 16:49:012019:11 кадастр номерлы җир кишәрлегендә рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрларыннан , кишәрлек чикләреннән торак йортка кадәр көнчыгыш ягыннан 5 метрдан 0 метрга кадәр һәм төньяк яктан 5 метрдан 0 метрга кадәр минималь тайпылышларны киметү өлешендә, читкә тайпылуга рөхсәт бирү турында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына карар кабул итәргә тәкъдим итәргә.

Эш төркеме рәисе урынбасары Ю.Н.Герасимов